**Контрольно - измерительные материалы**
**для проведения промежуточной аттестации**
**(тестирование)**
**по литературному чтению (татарскому)**
**(для изучающих татарский язык как родной)**
**4 класс**

## Спецификация

**Назначение проверочной работы -** оценить уровень сформированности предметных результатов по итогам усвоения программы по учебному предмету «Литературное чтение (на татарском языке)» обучающимися 4 класса.

**Структура КИМ**

Тест состоит из 2 частей: часть 1 включает 10 заданий с выбором ответа либо с записыванием краткого ответа; часть 2 состоит из заданий работы с текстом.

Время выполнения работы 45 минут.

**Кодификатор контрольно - измерительного материала**

| № задания | Проверяемые элементы содержания | Планируемые результаты | Максим. балл |
|---|---|---|---|
| Тест А1 | Знание литературных жанров | **предметные:** проверить полученные знания и умения<br>**коммуникативные:** умение размышлять и формулировать<br>**регулятивные:** умение достигать поставленной цели | 1 |
| А2 | Знание литературных жанров | | 1 |
| А3 | Умение соотносить автора и его произведения | | 1 |
| А4 | Умение определять литературный троп | | 1 |
| А5 | Знание содержания произведения | | 1 |
| А6 | Знание содержания произведения | | 1 |
| А7 | Умение определять жанры УНТ | | 1 |
| А8 | Умение соотносить содержание произведения и народной пословицы | | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| А 9 | Умение определять литературный жанр | **познавательные:** использование приобретенных знаний<br><br>**личностные:** понимание своих возможностей | 1 |
| А10 | Знание художественных средств | | 1 |
| Текст, задания В11 | Умение работать с текстом, выбирать конкретную информацию из текста | | 2 |
| В12 | Понимание и умение определять основную мысль текста | | 2 |
| В13 | Знание содержания текста, умение составлять план текста | | 2 |
| В14 | Умение рассуждать и выражать письменно свои мысли | | 2 |

**Критерии оценивания:**

| Балл | 16-18 балл | 13-15 балл | 9 -12 балл | 0 - 8 балл |
|---|---|---|---|---|
| % | 90-100 % | 70-89% | 45 -6 9% | 20-44% |
| Билге | “5” | “4” | “3” | “2” |

## I вариант

**1 нче өлеше (А)**

**А1**.*“Су буйларында бик күп йөрдек без,*
*Сак – сок булгачтын, дөнья гиздек без.”*
Бу өзек нинди әсәр жанрына керә?
а) миф;
в) бәет;
с) мәсәл.

**А2**. Мәсәл ничә кисәктән тора?
а) 1
в) 3
с) 2

**А3**. Кайсы рәттә А. Алиш әсәрләре урнашкан?
а) “Койрыклар”, “Чукмар белән Тукмар”, “Кемгә кирәк, кемгә кирәкми”.
в) “Яңгыр”, “Чишмә”, “Себерке”
с) “Ай һәм Кояш”, “Фатыйма белән Сандугач”, Яшь агач”

**А4**. Нәрсә ул гипербола?
а) әдәби әсәрләрдә чиктән тыш арттырып күрсәтү
в) мәзәк итеп, дусларча тәнкыйтьләп көлү
с) җансыз предметны җанландырып күрсәтү

**А5**. Д. Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар”, М.Зощенко “Мескен Федя” әсәрләрендә нинди тема чагыла?
а) бәхетле балачак
в) батырлык
с) сугыш

**А6**. Г.Тукай кайсы әсәрен татар халык әкиятенә нигезләнеп язган?
а) “Шүрәле”
в) “Су анасы”
с) “Кәҗә белән Сарык”

**А7.** Аллалар, баһадирлар, дөньяның барлыкка килүе турында борынгы халык әкиятләре (уйдырма, хыялый әйбер) ул – ...

а) мәсәл;
в) бәет;
с) миф.

**А8**. “Яхшылыкка - яхшылык” әйтеме нинди әсәр эчтәлегенә туры килә?

а) “Күгәрчен һәм малай” Р. Хафизова
в) “Дуслар” С.Әдһәмова
с) “Эт янында тиеннәр” Ә.Баян

**А9.** Х.Халиковның “Чыпчык баласы Чырчыр” әсәренең төре -

а) әкият;
б) шигырь;
в) сәхнә әсәре.

**А10**. Җанлы табигатьне сурәтләү нәрсә дип атала?

а) пейзаж;
б) натюрморт;
в) рәсем.

**2 нче өлеше (В)**

**Тәмле тел**

Ямьле җәй җиткән. Урман буйларында җиләкләр пешкән. Лилия энесе белән тагын әбиләренә кунакка кайткан. Алар әбиләре белән якындагы урман аланлыгына җиләккә йөри икән. Урманга барганда да, әбиләре аларга әкият сөйли, урман яңгыратып җырлый. Әбиләре әкиятләр, хикәяләр, әйтемнәр, мәкальләрне шулкадәр күп итеп белә икән, оныкларына әйтәсе килгән сүзен мәкаль яки әйтем белән генә җиткерә, ди.

- Яхшы сүз яшәртә, көч бирә, кулыңа сәләт һәм эш бирә,- дип, гел кабатлап тора әбиләре Лилия белән Ленарга.

- Балалар, әдәп башы-тел, шуны исегездә тотыгыз! Яхшы сүз кузгата җырларны, бизи ул, матурлый дөньяны!

Шулай дигән дә әбиләре оныкларына тәмле һәм тәмсез тел турында тагын бер әкият сөйләгән.

...Борын – борын заманда бер карт белән карчык яшәгән, ди. Бик озак яшәсәләр дә, болар бер генә тапкыр да сүзгә килешмәгән, ачуланышмаган, бик

тату көн иткән. Күз карашларыннан аңлашып, яратышып торалар икән. Шулай беркөнне карт карчыгын янә бер кат сынап карамакчы булган.

- Карчык, - дигән карт, - дөньядагы иң тәмле ризыкны пешер әле!

Карчыгы аңа сыер теле пешереп биргән.

- Дөрес, - дигән карт, - дөньяда телдән дә тәмле, телдән дә татлы нәрсә юк!

Бераз вакыт узгач, карт карчыгын тагын сынап карамакчы булган.

- Син миңа дөньядагы иң тәмле ризыкны ашаттың, анысы өчен рәхмәт, дигән, - хәзер инде тәмсез ризыкны пешер!

Карчык бу юлы да картына сыер теле пешергән.

- Рәхмәт, карчык, - дигән карт, - син – дөньядагы иң зирәк, иң акыллы хатын. Телдән дә тәмле, шулай ук телдән дә тәмсез нәрсә юк. Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел!

- Менә шулай, балалар. Яхшы сүз – шифалы, тылсымлы, ул юа яраны, борчуны! Яхшы сүз тауларны күтәрә, давыллар аркылы үткәрә, тәмле телле булыгыз! – дип тәмамлаган сүзен әби...

Илүсә Нәбиуллина

В11. Әкияттәге татар халык мәкальләрен табып яз.

________________________________________________

________________________________________________

В12. Төп фикер әкиятнең кайсы өлешендә, шул абзацны табып яз.

________________________________________________

________________________________________________

В13. Хикәянең планын дөрес итеп төзеп яз (җөмләләр саннарын).

1. Карт карчыгын сынаган. 2. Лилия белән Ленар әбиләренә кунакка кайткан. 3. Әби үзен тәмамлаган. 4. Әби әкият сөйләгән. 5. Әби белән бабай тату яшәгәннәр.

________________________________________________

В14. Ни өчен бабай әбигә “Дөньяда телдән дә тәмле, телдән дә татлы нәрсә юк”-ди?

________________________________________________

________________________________________________

**Дөрес җаваплар**

| № | җавап |
|---|---|
| А1 | в |
| А2 | с |
| А3 | а |
| А4 | а |
| А5 | с |
| А6 | а |
| А7 | с |
| А8 | в |
| А9 | а |
| А10 | а |